**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районынын Иске Имән авыл җирлеге**

---

**КАРАР**
**18.12.2025 ел**

**КАРАР**
**№ 22**

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен акчалата тәэмин итү турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 карары нигезендә, Районның Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 8 августындагы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен акчалата тәэмин итү турында» 7 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә (2018 елның 12 декабрендәге 14 номерлы, 2020 елның 6 октябрендәге 7 номерлы, 2024 елның 21 июнендәге 10 номерлы, 2024 елның 1 ноябрендәге 16 номерлы, 2025 елның 30 апрелендәге 8 номерлы карарларда кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче кушымтаның 2 пунктында «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге карарны игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Ә.Исламова